# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ V ЧАКЫРЫЛЫШ X СЕССИЯСЕ

## К А Р А Р № 50

Мөслим авылы «30» август 2026 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының закон чыгару инициативасы турында**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 13, 19, 26 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим районының Удобновка авылын бетерергә.
2. Татарстан Республикасы Мөслим районының Үрнәк авылын бетерергә.
3. «Татарстан Республикасы Мөслим районының аерым авыл торак пунктларын бетерү һәм «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы проектын караганда Мөслим муниципаль районы Советы вәкиле итеп Әхмәтҗанов Азат Мөҗәһит улын - Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасарын билгеләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.М. Әхмәтҗановка йөкләргә

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,<br>
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р.Хуҗин